# Микология-грек сүзе

«Мико»-гөмбә


“Логос”-фән



# Ә нәрсә ул гөмбә?

Үсемлекме?

Хайванмы?






# Гөмбәнең тарихы

**Гөмбәләр турында инде безнең эрага кадәр 4 гасырда ук мәгълүмат тупланылган. Шул вакытта ук аларны өйрәнә башлаганнар.**

**Борынгы вакытларда гөмбәләрне “губы” дип йөрткәннәр.Аларның кырыйлары ирен формасында булганга күрә шулай атаганнар. Борынгы заманда гөмбәләрне чыктан, яшен сугудан, әйбер черегәннән барлыкка килә дип уйлаганнар. Һәм 19 гасырдан гөмбәләрне аерым патшалык итеп йөртә башлыйлар**.

# Гөмбәче сүзлеге

Гөмбә - гриб

Гөмбәлек - грибница

Гөмбәче - грибник







# Гөмбәнең төзелеше



**Эшләпә**

**Аяк (төп)**

**Гөмбәлек**

# Организмга файдасы

Гөмбәләр аксымнарга бик бай.

Аларда тимер, калий, кальций, йод, фосфор һәм цинк та бар. Шуңа күрә алар организм өчен бик файдалы.

# Гөмбә төрләре








# Күзгә күренми торган гөмбәләр

**Гөмбәләр дөньясы бай һәм төрле-төрле. Кеше гөмбәләр белән урманда гына очрашмый. Ипи кисәге күгәрдеме- бу гөмбә. Дымлы бүлмәдә стенага яшел әйберләр үсеп чыктымы – бу да гөмбә, алма бозылдымы бу да гөмбә эше. Иске кәгазьләрдә дә гөмбәчекләр яши икән. Анда яшәүче гөмбәчекләр кешене җиңелчә генә саташтыра, аңны үзгәртә, кәефне күтәрә. Менә шуңа күрә дә безгә күптәнге китаплар яңаларына караганда кызыграк тоела икән.**

# Гөмбә җыю кагыйдәләре

- **Гөмбәләрне  таяк белән эзләргә;**
- **Яфракларыннан чистартып, гөмбәне таныргa, ашарга яраклымы яки юкмы икәнен ачыкларга;**
- **-Пычак белән кисеп алырга;**
- **-Эшләпәсен аска каратып кәрҗингә урнаштырырга;**
- **-Урманның кай ягына таба кереп киткәнеңне белергә.Адашу, югалу куркынычы яный!**

# Гөмбәнең табигатькә файдасы

- Бик күп хайваннарга азык булып тора;
- Агулы гөмбәләр белән кайбер хайваннар дәвалана;
- Бөҗәкләр өчен яшәү урыны;
- Кечкенә җәнлекләр һәм кошлар гөмбә эшләпәсенә җыелган суны эчәләр.
- Гөмбәләр урманга бик кирәк. Аларның җепләре, агач тамырлары белән кушылып, туфрактан туклыклы матдәләр һәм су суырырга булышалар.



